
ISSN 0868-4545



Салават күпере







Зилә Вәлиева,
Татарстан Республикасы матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм массакүләм коммуникация чаралары министры.

«Салават күпере»нең ун еллыгы, беренче чиратта, балалар бәйрәме. Журнал туксанынчы елның март аеннан бирле сабыйларга ай саен бәйрәм ясап килә инде. Әлеге бәйрәм күктәге Салават күпере кебек гел матур төсләрдән генә тора. Күктә Салават күпере балкый, җирдә исә «Салават күпере» журналы үз укучыларын сөендерә!

Барчагызның да бәйрәме котлы булсын! Журналистларга иҗат уңышлары телим!







Зиннур Хөснияр,
баш мөхәррир.

«Салават күпере» битләрендә дөньяга килгән һәм бик тә бик зур биштәр аскан Шүрәле агайга да ун яшь тулган икән инде! Биштәре һаман буш түгел: мәзәк-әйтемнәр, тапкыр мәкальләр һәм дә кызыклы әкият-хикәяләр белән дыңгычлап тулган ул. Биштәрдән күптән түгел генә «Сыбызгы» да килеп чыкты әле. «Салават күпере» журналы янына ул биштәр эченә «Сыбызгы» кушымтасы да сыйган икән!

Сөенегез, балалар, куаныгыз! Хәзер сиңа да ун яшь булса, тагын ун елдан егерме яшь булачак! «Салават күпере» белән бергә-бергә үсәргә язсын сиңа!







«Салават күпере»нә 10 яшь!


© "Салават күпере", 2000 ел



4/91
Апрель
Салават күпере



Балалар журналы
Салават күпере



Балалар журналы
Салават күпере



Балалар журналы
Салават күпере



9/91
Сентябрь
Салават күпере




Балалар журналы
Салават күпере
БИШЕГЕМ ЯШЬ


Балалар журналы
Салават күпере


Балалар журналы
Салават күпере


Балалар журналы
Салават күпере


Балалар журналы
Салават күпере



Балалар журналы
Салават күпере


Балалар журналы
Салават күпере



Журналыбыз куанычлары




Дилә (3 яшь), Искәндәр (5 яшь):

Диңгез кирәк түгел безгә,
Кирәк түгел елга.
Чиләк белән бидонда да
Мөмкин коенырга.


Алисә (9 яшь, үз шигыре):

Кояш нигә елмая?
Шуны беләсем килә.
Җавап биргән кешегә
«Рәхмәт!» диясем килә.






Булат (10 яшь):




Печән ташый-ташый-ташый
Арып беттем бит, малай...
Бозау һаман җиңнән тарта:
– Абый, печән бир, давай!



Миләүшә (8 яшь):

Мавыгыплар укыйсың гел –
Кызыктыр... Сизәм инде...
Миләүшә апам, зинһар ла,
Миңа да сөйлә инде!


Динә (5 яшь):

Моторы янды: «Тыр-тыр-тыр...
Тыр-рыйн, тыр-рыйн!»... Тырышам,
Тырышмыйча булмый. Мин бит
Йөк ташырга булышам.





«Һәрчак чиста булу кирәк!» –
Диеп ашап утырам.
Түш япкычымны да әллә
Салыйм микән дип торам.



Аста – чүлмәк, ә башымда
Шул чүлмәкнең капкачы.
Кайсыгыз торгыза инде,
Үзем торып чапканчы?!




Аптыраган… Нишләргә? –
Әни чәчне чылата…
Шампунь белән юыйк әле,
Сабын күзне елата!



Ике курчак арасында
Курчак кебек үзем дә.
Кайсыбыз тизрәк үсәсен,
Йә, кайсыгыз тиз белә?



Кыяфәт шәп,
Тавыш бар.
Безгә сәхнә генә тар.



Бассейн дигән диңгез бу,
Шунда йөзәбез әле.
«Көчле җил-давыл» чыкмакчы.
Әлегә түзәбез әле.



Бүгенге сәхифәдәге рәсемнәрне төрле төбәктә яшәүче укучыларыбыз «Салават күпере»нең зур бәйрәме белән котлап җибәргәннәр.





Ләйсән Әхмәтҗанова, 9 яшь. Казан.




Айгөл Низамова, 13 яшь. Биектау.



Дания Гыйләҗева, 8 яшь. Казан.



Алсу Нургалиева, 12 яшь. Казан.



Гөлия Вәлиуллина, 10 яшь.
Яшел Үзән.



Катя Вшивцева, 7 яшь.
Казан.

Бу урманны кем яккан?
Ник ялкын уйный җилдә?
Җәнлекләрне кызганам,
Минем елыйсым килә.



Алсу Рәкыйпова.
Казан.

Кояш чыга, таң ата,
Ай да йокларга ята.
Ай апа – әниләре,
Йолдызлар – бәбиләре,
Күк аларның өйләре.




Альбина Хәйруллина, 9 яшь.
Казан.





Джанни Родари

Әкият сөйли белмәүче бабай



–Яшәгән, ди, Сары Калфак исемле бер бәләкәй кыз...

– Сары түгел, ә Кызыл!

– Ә... әйе шул! Кызыл Калфак... Әнисе чакырып алган да моны, әйткән: «Кызым, Яшел Калфак...»

– Юк инде! Кызыл, дидем бит...

– Әйе, әйе, Кызыл. Дамирә түткәең янына барырсың, аңа бәрәңге кабыклары илтерсең...

– Юк! Алай түгел. Әнисе әйткән кызга: «Әбиең янына барып кайтырсың, аңа бодай кабартмасы илтерсең!» – дигән...

– Ярый, шулай булсын. Кыз урманга киткән һәм анда жирафны очраткан.

– Тагын бутадың инде! Ул жирафны түгел, бүрене очраткан!

– Шуннан бүре сораган кыздан: «Алты сигезең ничә була?» – дигән...

– Юк шул, алай түгел шул менә! Кая барасың? – дип сораган бүре.

– Син хаклы. Шуннан соң Кара Калфак болай дип җавап кайтарган...

– Ул Кызыл булган, Кызыл, Кызыл Калфак!

– Ярар, ярар. Кызыл икән – Кызыл. Мин базарга помидор алырга барам... – дигән кыз.

– Бөтенләй алай түгел! Мин әбием янына бара идем... Адаштым... – дигән ул.

– Дөрес. Ә ат аңа әйтә икән...

– Нинди ат? Бүре дидем бит инде.

– Әлбәттә, бүре! Менә шул әйтә икән: «Утыр 13 нче трамвайга, Ирек мәйданына кадәр бар, уңга борылырсың, борылгач, аска таба төшеп китә торган баскыч күрерсең, шуның янында гына бер тәңкә акча табарсың. Баскычка игътибар итеп торма, акчаны иелеп ал да туңдырма саткан җиргә йөгер!»

– Беләсеңме, бабакай, син бөтенләй әкият сөйли белмисең! Ә менә туңдырманы син миңа барыбер алып бирәчәксең!

– Ярый. Мә, алайса, сиңа акча.

Бабай акча суздырды да янә гәзит укырга тотынды.

Урысчадан **Ләбиб Лерон** тәрҗемә кылды.

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Чарасын тапкан



Мәзәк

Бер нәни кыз әнисенә әйтә икән:

– Әни! Сөт чиләгенә тычкан төшкән!

– Төшсә ни хәл итәсең инде, кызым? Алып ташлагансыңдыр бит? – дигән әнисе.


– Юк, тотарга курыктым. Тычканны тотарга дип песине дә чиләккә ташладым! – дигән нәни кыз.

Рәссам Фәрит ЯКУПОВ

Әкият башы



И-и, карагыз, мич астыннан ни аулап
Килеп чыкты әнә мәче мияулап?..
Бу тик әкиятнең баласы,
Коймак изә әбисе,
Таба майлый анасы.
Табагачтыр, коймактыр,
Сөйләгәнне тыңлап тор.
Иләктер дә чиләктер,
Колагыннан эләктер.



Рәссам Рушан ШӘМСЕТДИН

Үткәннән бер сәхифә

Ага базар



«Вакыт машинасы» Булат белән Сөмбелне мең дә бер йөз еллар элгәре заманнарга алып китте. Алар Бөек Болгар шәһәренең калын диварларына карап тордылар да кире елга ярына борылдылар. Анда бик күп кеше җыелган иде. Якынрак килгәч, аның зур базар икәнен белделәр. Ул Ага базар дип атала икән. Халык бөтен болынны биләп алган. Тавыш, ыгы-зыгы. Берәүләр сата, берәүләр ала. Күптән түгел генә Булат әтисенә ияреп Казан базарына барган иде. «Мең ел үтсә дә, дөнья үзгәрми икән», – дип уйлады ул.

Булат бер мизгелгә күзләрен учы белән каплады. Алтын кылычларның кояшта җемелдәве күзен камаштырган иде. Кара мыеклы сатучы абый елмаеп Булатны якын килергә чакыра. Янәшәсенә сызгырып оча торган уклар өелгән, озын сөңгеләр сөяп куелган, бизәкләп эшләнгән калканнар тезелгән.

Ә Сөмбел Булатның җиңеннән тотып читкә тарта. Анда елкылдап торган болгар күненнән тегелгән читекләр саталар. Янәшәсендә үк сусар, кеш тиреләре җемелди, йорт биеклеге итеп паласлар өелгән.

Кинәт халык арасында ыгы-зыгы купты. Ярга җилкәннәрен киергән зур көймә килеп туктады. «Багдадтан килгәннәр!» – дигән тавышлар ишетелде. Көймәгә басма сузылды. Чалмалы гарәпләр ярга чыга башлады. Кайсыдыр мәчеттән: «Аллаһы әкбәр!» – дигән азан тавышы яңгырады.

Болгар-Биләр диясез,
Болгарданмы киләсез?
Болгар елкыларын һәйдәп,
Һинд илләрен гизәсез.

Җукә ләнгәс – кәрәз балта,
Җам-аяклар – ачы балта,
Энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут
Агыла шәһри Болгарга.

Сәхифә **Р.Зәйдулла** хикәяләвендә бирелә.

Канатлы талант

Лиана Әмирханова



«Пескәй-90» конкурсы җиңүчесе Лиана Әмирханова.

Җил малае

*Җил малае ни ди ул,
Нигә шулай улый ул?
Өй артында ни даулый да,
Ник үкереп елый ул?*

*Белдем, белдем, ул малайның
Уйныйсы килгән икән.
Төне буе карлар өеп
Тау ясап куйган икән.*

Кар суы

*Челтер-челтер, елтыр-елтыр
Кар сулары юл яра.
– Әйдә, – ди миңа кар суы, –
Китәм, уйнамый калма.*

*Шырпы кабыннан тиз генә,
Мин көймә ясап алдым.
Җилкәннәр куеп көймәне
Ерганак суга салдым.*

*Көймәне челтер кар суы
Үз артыннан ияртте.
Үзе белән уйнаганга
Миңа рәхмәтен әйтте.*



«Салават күпере»нә ничә яшь? Әлбәттә, сорау биреп торасыбыз да юк – 10 яшь! Моннан ун ел элек, беренче әкияте һәм шигырьләре безнең журналыбызның «Былбыл» сәхифәсендә дөнья күргәндә Лиана да шул яшьтә иде.

Лиана Әмирханова – Казан кызы. Бүген инде ул – Татарстан Язучылар берлегенең иң яшь әгъзаларыннан берсе. Кайчандыр журналыбыз битләрендә канат ныгыткан Лианага затлы очышлар гына насыйп булуын телибез.

Ул бездә эшләде...





Рафис КОРБАН

Минем дә җырым бар...

Һәр кемнең бар
Үз җыры.
Җырлый кое
Чыгыры.

Көянтә дә,
Чиләк тә.
Кошлар җырлый
Тирәктә.

Үз җыры бар
Җилнең дә.
Үз җырым бар
Минем дә.

Нинди җырмы?
Ул җырмы? –
Су ташучы
Кыз җыры!

Өстә шул

Беләсезме,
Мин үсәм!
Күзгә күренеп үсәм.
Хәзер инде шүрлеккә дә
Буем җитә үрелсәм.

Буең җиткәч, рәхәт икән –
Юк сорап ялынасы.
Алмагачның алмасын да
Үзәсең дә аласың.

Тик күккә һич буем җитми,
Ничек кенә үссәм дә.
Күк өстә шул, биектә шул
Ул бөтенесеннән дә.



Балачактан туп-туры балалар әдәбиятына, балалар матбугатына килгән шагыйрь Рафис Корбан да моннан ун ел элек журналның тәүге саннарын эшләүдә катнашты. Кызыклы шигырьләр, әкияти пьесалар язучы әлеге шагыйребез бүген безнең Бәйрәмебез кунагы.





Зиннур Хөснияр,
«Салават күпере» журналы һәм
«Таһир-Зөһрә» гәзитенең баш мөхәррире.

Кадерле дускай!

Мин сине, олуг Бәйрәм уңаеннан, «Салават күпере» журналын оештыручылар һәм аның тәүге саннарын чыгаручылар, журналханәдә бүген дә армый-талмый эшләүчеләр белән якыннанрак таныштырырга булдым әле.

Зиннур Хөснияр. Бу аның – әдәби кушаматы. Тулы исем фамилиясе болай: Зиннур Зыятдин улы Хөснетдинов. Дөбъяз ягыннан, ягъни Биектау районының Бикнарат авылыннан. 1961 елның ямьле җәй уртасында туган. Димәк, йолдызнамә буенча Кысла була инде. Мәктәптә укыган вакытларында ук шигырьләр, хикәяләр язган. Казан педагогия институтын (хәзер университет дип атала) тәмамлаган. «Ялкын» журналханәсендә, радиокомитетта, Татарстан китап нәшриятында эшләгән, армиядә хезмәт иткән...

Озын сүзнең кыскасы шул: сине ошбу сәхифәдәге фотосурәтләр белән танышырга чакырам.

Шүрәле оныгы Шүрвәли.



Бар иде яп-яшь чаклар...



Әтием, әнием һәм сеңелем белән.



Армиядә. Ял тәтегән вакыт.



Гомеремнең иң гүзәл мизгеле.



1988 елның бер истәлегедер бу.



Туганнар бергә җыелган мәл. 1988.





Бердәнберләрем: хатыным Нурия, кызым Зилә һәм улым Булат.



Көтү көткән бар ла ул...





Ләбиб Лерон,

«Салават күпере» журналының әдәби бүлек мөхәррире.

Ләбиб абый Леронның чын исемен беләсеңме? Белмәсәң әйтәм, белсәң исеңә төшерәм: Лемон. Тулырак әйтсәк мондый: Лемон Лерон улы Леронов. Сәер яңгырый, әйеме?! Хәер, монысы аның әтисе кушкан исем. Әле әнисе кушкан исем дә бар: Ленарис. Кайсы исеме белән дәшсәләр дә борылып карый Ләбиб абый. Ләбиб дигәннән... Ләбиб – монысын Казан университетында укыган чагында дуслары кушкан. Димәк, без белгән Ләбиб Лерон исеме – әдәби кушамат була инде.

Мәктәптә укыганда сигезенче сыйныфка чаклы аның бер генә хыялы булган – космонавт булу. Шул хакта ул «Яшь ленинчы»да (хәзерге «Сабантуй») шигырь дә бастырган. Шуннан соң ул шагыйрь булырга хыялланган...

Тумышы белән Мөслим районыннан булса да, ул үзен Актаныш районының Олыймән авылыннан дип саный. 1961 елда туган. Йолдызлыгы – Чаян. «Яшь ленинчы»да, телевидениедә эшләгән...

Ләбиб абый да – безнең дус. Татарстан телевидениесе аның «Урмандагы тамаша» дигән әкият-пьесасы буенча куелган спектакльне әллә ничә мәртәбә кабатлап күрсәтте инде. «Шүрулла белән Шүрвәли», «Борчак боткасы» дигән кызык-мызык әкиятләре дә безнең хакта.

Шүрвәли.



«Моряк» Ләбиб әнисе Шәргыя апа белән.

Ләбибкә «техника җене» кагылган чаклар:



вилсәпидтә...



...күрше малайлары белән матайда. 1978.



...әнисенең энесе Рөстәм абый машинасы янында...



...үзе генә йөрткән Т-40 тракторы янәшәсендә.



Уйларның уелган мәле.




Ләбиб – студентларның төзелеш отрядында бригадир.





Университетны тәмамлаганнан соң бер айлык армия хезмәтендә.



Шигырьләр укыган чак.



Ләбиб хатыны Фидания, кызлары Айсылу, Ләйлә һәм улы Бәхтияр. 1996.





Фирая Бәдретдин,

«Салават күпере» журналының баш мөхәррир урынбасары.

«Балачакта укыган китапларыгыздан кайсысы бигрәк тә истә калды?»

Бервакыт Фирая ападан шулай дип сораган идем. Ул уйланып та тормыйча: «Шүрәле», – диде. Габдулла Тукайның бабам турында язган мәшһүр «Шүрәле» әкияте турында әйтүе инде. Шундый җавап ишеткәч, җанга рәхәт булып китте. Фирая апаны болай да ярата идем, ихтирамым тагын да артты...

Фирая апа Бәдретдин (без аны Фирая Равил кызы Бәдретдинова дип тә белик) Балтач районының Көекбаш авылында (ни кызганыч, бу матур авыл дөньяда юк икән инде) туган. Данлыклы Карадуган мәктәбендә укыган, Казан университетын тәмамлаган, байтак еллар «Яшь ленинчы»да эшләгән... Йолдызлыгы – Кучкар. Туган елы... Әйем лә, әйтмим әле. Минем әби әйтә: «Хатын-кызның яшен сорамыйлар...» ди... Бер-бер сере бардыр инде...

Шүрвәли.

Көтелмәгән хәбәр (бу хакта Шүрвәли белми иде әле): ошбу елның февралендә Фирая Равил кызы Бәдретдинова әниләребезнең, әбиләр-апаларның, туташ-сеңелләрнең яраткан журналы «Сөембикә»гә баш мөхәррир булып китте. Без Аны яңа җаваплы эшкә урнашуы белән чын күңелдән котлыйбыз һәм Аңа һәрвакыт уңышлар гына юлдаш булуын телибез!

«Салават күпере» хезмәткәрләре.



Алгы рәттәге ике кызчыкның берсе – пионерка Фирая. 1969.



Пионерлагерьга Фираяның хәл-әхвәлен белергә апасы Фәйрүзә, сеңелесе Резидә килгән. 1969.



Үсмер чак.



Генерал Фатих Булатов белән очрашу. Сурәттәге иң кечкенә кыз – безнең Фираябыз булыр.




Яшь чак – студент чак. 1980.



Ашагыз, аккошларым.








Әнисе Фәүзия, сеңелесе Резидә, кызы Фәридә белән.



Кызчыгы – бөтерчеге Фәридә белән.



Фәрит Муллахмәт,

«Салават күпере» журналының баш рәссамы.

Фәрит абый матур-матур рәсемнәрен элек тә күп ясаган. «Элек» дип, «Салават күпере»ндә эшли башлаганчы ук дип әйтүем инде. Журналханәдә эшләү дәверендә ул отыры кызып китте: «Салават күпере» саен аның рәсемнәре басыла, өстәвенә, китап нәшриятына китаплар бизәп тапшыра... Үзе генә ясаса бер хәл, башка оста рәссамнарны да «Салават күпере»нә эшкә җигә...

Җай чыкканда мактаныйм әле: Фәрит абый безнең турыда да хәттин күп сурәт ясады. Зиннур абый Хөснияр белән Ләбиб абый Лерон бергә чыгарган «Шүрәле шаяруы» (1996 ел, № 4-5) китап-журналын да ул бизәде...

Фәрит абый (Фәрит Ясәви улы Муллахмәтов) 1949 елда Казанда туган. Яңа Бистәдә. Мәктәптән соң Казан сәнгать училищесын тәмамлаган. Армия сафларында булган. Рәссамнар фондында 20 елдан артык (әйтергә генә ансат, әйеме?) рәссам – бизәүче булып эшләгән. 1993 елның июнендә «Салават күпере» журналханәсенә эшкә килде...

Йолдызлыгы – Кучкар.

Кыскасы, кадерле дускай, әйдә, Фәрит абыйның гаилә фотоальбомына күз салыйк әле...

Шүрәли.



Әнием Сания, әтием Ясәви, апам Фәридә белән.




Без биш бала үстек әти-әни белән...



Ефрейтор булган чаклар.



Училище истәлеге: мин сабакташларыма политуку үткәрәм.



Без бу: Фәрит + Әлфия.



Туган-тумачаларым, пләмәшләр белән.



Минем кадерлеләрем – улларым Адель белән Айдар.







Кече улым Айдар, олы улымның хатыны Илдария, оныгым – татлыдан-татлы Эмиль.

Безнекеләр –

Кадерле дускай, ошбу сәхифәдә «Салават күпере»н һәм журнал каршында нәшер ителүче «Таһир-Зөһрә» гәзитен чыгаручы хезмәттәшләребезнең хәзерге һәм бала чактагы, яшь чактагы



Вакыйф Нуриев,
баш мөхәррир урынбасары.


Таныш бул, нәни дускай: журналыбызның баш мөхәррир урынбасары булып Вакыйф Вәкил улы Нуриев безгә эшкә килде. Моңа хәтле ул «Шәһри Казан», аңарчы «Яшь ленинчы» («Сабантуй») гәзитләрендә эшләгән иде.

Туган төбәге – Арча районының Сеҗе авылы.

Без Вакыйфка «Рәхим ит безнең арабызга, бергә-бергә, озын-озак, дустанә эшләргә язсын!» дибез.



Рәйсә Юсупова,
бүлек мөхәррире.



Мөнирә Кузиева,
компьютер дизайнеры.







Илсөяр Иксанова,
бүлек мөхәррире.







Ренат Гаффар,
бүлек мөхәррире.











Диләрә Нәүрузова,
рәссам-дизайнер.

Үзебезнекеләр!

фотосурәтләре бирелде. Ул вакыттагы рәсемнәр астына исемнәрне «юри» куймадык,сиңа бер шөгыль булсын әле дидек. Йә,абый-апаларның бала чакларын,яшь вакытларын ялгышмыйча табып карачы.








Альбина Зиннәтуллина,
гамәли хезмәткәр.





Гүзәл Сәетова,
компьютер операторы.







Лилия Галәвиева,
гамәли хезмәткәр.







Рәмзия Салих,
исәп-хисапчы.





Нурия Хөснетдинова,
бүлек мөхәррире.









Безгә таныш

Мактанып әйтсәк-әйтмәсәк тә син моны үзең дә анык белеп-күреп торасың: журналыбыз битләрендә кызыклы, матур рәсемнәр бик күп, шулай бит?! Аларны «Салават күпере»нә (димәк, синең өчен дә!) безнең дусларыбыз-рәссамнар ясап кына тора.

Уңышлар юлдаш булсын үзегезгә, Бәйрәм бергә-бергә узсын, хөрмәтле дуслар!




Айдар Үтәгән.



Григорий Әйдинов.







Юрий Денисов.



Светлана Привина.




Илдар Нәфиев.


рәссамнар


Рушан Шәмсетдин.


Илдар Әхмәди.


Светлана Ибраһимова.


Фәрит Якупов.


Иван Воробьев.


Надир Әлмиев.

Журналдагы шаян Шүрәленең төрле халәттәге сурәтләрен Юрий Денисов ясады, авторы күрсәтелмәгән бүтән бизәлешләрне Фәрит Муллахмәт эшләде.

Салават күпере

2-3(120-121) — 2000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 1нче битендә
Юрий ДЕНИСОВ рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 10.3.2000 ел.
Басарга кул куелды 13.3.2000 ел.
Кәгазь форматы 84x108 1/16.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 16467 данә. Заказ Э-88.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

